# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2007 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, №12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"кешеләр күп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чаралары – гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы булу, гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү һәм халыкның үз-үзен тоту кагыйдәләре турындагы аудио- һәм (яки) аудиовизуаль, шулай ук бүтән хәбәрләрне кабул итүне, эшкәртүне һәм тапшыруны гамәлгә ашыручы махсус эшләнгән техник җайланмалар.";

2) 3 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар администрациясе массакүләм мәгълүмат чаралары аша, шул исәптән кешеләр күп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын кулланып, һәм бүтән төрле каналлар буенча халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау торышы һәм аларның иминлеген тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында, фараз кылына торган һәм барлыкка килгән

гадәттән тыш хәлләр турында, халыкны алардан яклау алымнары һәм ысуллары турында оператив һәм дөрес мәгълүмат бирергә тиеш." ;

3) 9 статьяның беренче өлешендә:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрдән халыкны һәм территорияләрне яклау өлкәсендә мәгълүмат җыюны һәм алмашуны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыру, муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы булу яки барлыкка килү турында кешеләр күп җыела торган урыннарда үз вакытында халыкка хәбәр итүне һәм мәгълүмат бирүне тәэмин итү, шул исәптән халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын кулланып;";

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органына кешеләр күп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру өчен участоклар бирүгә һәм (яки) мондый чараларны урнаштыруга, шулай ук халыкка гадәттән тыш хәлләр турында үз вакытында хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү, гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү максатларында, булган техник җайланмаларны массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясен тарату өчен бирүгә, эфир вакытын бирүгә ярдәм күрсәтү;

эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларын резервлау.";

4) 10 статьяда:

сигезенче абзацта "мәгълүмат бирүне" сүзләреннән соң ", шул исәптән кешеләр күп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын кулланып" сүзләрен өстәргә;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"кешеләр күп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру өчен участоклар бирүгә һәм (яки) мондый чараларны урнаштыруга халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органына, шулай ук халыкка гадәттән тыш хәлләр турында үз вакытында хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү, гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү максатларында, булган техник җайланмаларны массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясен тарату өчен бирүгә, эфир вакытын бирүгә ярдәм күрсәтү.";

5) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"13 статья. **Аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы, уникаль объектларны проектлау документларына дәүләт экспертизасы**

Аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы, уникаль объектларны проектлау документлары шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт экспертизасы үтәргә тиеш.";

6) 16 статьяның икенче өлешендәге "шулай ук яшәү урыны буенча" сүзләрен "яшәү урыны буенча, шулай ук кешеләр күп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын кулланып" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан,Кремль
2007 елның 8 ноябре

№ 50-ТРЗ